Нурмөхәммәтова, А. Күзге тамаша : [6нчы шәһәр китапханәсендә балалар өчен үткәрелгән кызыклы чаралар турында] / А. Нурмөхәммәтова // Көмеш кыңгырау. – 2025. - № 44. – Б. 2.



# Көзге тамаша

Китапханәбездә балалар өчен кызыклы чаралар узды. Башлангыч сыйныфларга – «Көзге тамаша» театраль күренеше, урта һәм югары сыйныф укучыларына «Сугыш юллары буйлап», «Китап серләре», «Профессия сайлыйбыз» квест-уеннары оештырдык. Укучылар китапханәнең төрле бүлекләрендә булдылар һәм мавыктыргыч биремнәр үтәделәр. Яшь китап сөючеләр үзләренең тапкырлыгын һәм белемен күрсәтте, шулай ук яңа мәгълүмат та туплады. Көзге каникуллар менә шулай файдалы үтте, дуслар!

**А. НУРМӨХӘММӘТОВА,**
*Яр Чаллы шәһәре,*
*Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәренең 6нчы китапханә-филиалы хезмәткәре.*